**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының
мәгариф идарәләре җитәкчеләренә

Мәктәп укучылары арасында
«Илһам» бөтенроссия яшь
язучылар бәйгесен үткәрү турында

Татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, барлау, яшь язучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү максатыннан, 2014-2015 нче уку елында Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә татар телендә иҗат итүче мәктәп укучылары арасында «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесен уздыра.

Бәйгедә катнашырга теләүче укучылар иҗади эшләрен электрон вариантта ilhambeygese2015@gmail.com адресына 31 нче гыйнварга кадәр җибәрергә тиеш. 1 нче турда җиңеп чыгучыларга бәйге лауреаты исеме бирелә, әсәрләре бәйге нәтиҗәсендә әзерләнәчәк әдәби альманахка кертелә, 1-3 нче урыннар алучыларга Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары һәм премияләр тапшырыла.

Йомгаклау кичәсен уздыру көне өстәмә рәвештә игълан ителәчәк.

Хәбәрләшү өчен телефоннар: (843)554-32-34, 89172342825, 294-95-10.

Нигезләмә татар телендә теркәлә.

Кушымта 1: «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар нигезләмәсе 4 биттә 1 нөсхәдә.

Кушымта 2: Анкета 1 биттә 1 нөсхәдә.

Министр урынбасары И.Р. Мөхәммәтов

Л.М. Шакирова,
8(843)294-95-10

Кушымта 1

# «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе
# нигезләмәсе

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесен (алга таба – Бәйге) үткәрә.

## 2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Бәйге уздыруның төп максатлары:

- татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү;
- укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту;
- әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, барлау;
- яшь язучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү.

## 3. Бәйгене оештыру комитеты

3.1. Бәйгене үткәрү өчен Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты, яшьләр өчен чыга торган массакүләм мәгълүмат чаралары, белем оешмалары вәкилләреннән торган оештыру комитеты төзелә.

3.2. Оештыру комитеты Бәйге турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы сайты, республика муниципаль районнарының мәгариф идарәләре яки бүлекләре аша мәктәпләргә җибәрелгән мәгълүмат хатлары, балалар һәм яшьүсмерләр өчен чыга торган татар газета-журналлары аша мәктәп укучыларына, киң җәмәгатьчелеккә җиткерә, әсәрләрне туплауны һәм жюри эшчәнлеген оештыра. 2 нче турга чакырылган җиңүчеләр өчен татар язучылары, шагыйрьләр белән очрашулар, остаханәләр, түгәрәк өстәлләр һәм бүләкләү тантанасын үткәрә, яшь язучыларның әсәрләрен таныта.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## 4. Экспертлар төркеме һәм жюри

4.1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә бәйгегә килгән эшләрне бәяләү өчен экспертлар төркеме билгеләнә һәм жюри төзелә. Экспертлар һәм жюри әгъзалары яшь һәм тәҗрибәле иҗатчылар, галимнәр, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, мәктәп җитәкчеләре һәм мөгаллимнәрдән сайлана.

4.2. Эшләр экспертларга оештыру комитеты тарафыннан шифрлап тапшырыла. Һәр эш 3 эксперт тарафыннан бәяләнә. Бәяләүдә гаделлек, объективлык саклау максат итеп куела.

4.3. Әсәрләр экспертлар төркеме һәм жюри әгъзалары тарафыннан алдан әзерләнгән критерийлар нигезендә 10 ар балл исәбеннән бәяләнә. Баллар куелган бәяләү кәгазе, һәр эксперт тарафыннан имзаланып, оештыру комитетына тапшырыла.

Әгәр экспертлар бәяләмәсендә берничә әсәр бер үк баллга ия булса, алар жюри әгъзалары тарафыннан тавыш бирү юлы белән бәяләнә, тавышлар тигез булган очракта жюри рәисе тавышы өстенлек ала.

Жюри карары буенча дәгъвалар кабул ителми.

## 5. Катнашучыларга һәм иҗади эшләргә таләпләр

5.1. Бәйгедә татар телендә иҗат итүче мәктәп укучылары катнаша ала.

5.2. Бәйгегә җибәрелгән әсәрләр өч яшь категориясенә бүленеп карала:

1. *5 - 7 сыйныфлар*;
2. *8 - 9 сыйныфлар*;
3. *10-11 сыйныфлар*.

Башлангыч сыйныф укучылары, конкурстан тыш катнашып, кызыксындыру бүләгенә ия булырга мөмкин.

5.3. Бәйге түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1. *Яшь шагыйрь (һәр яшь категориясендә);*
2. *Яшь прозаик (һәр яшь категориясендә);*
3. *Яшь драматург (8-9, 10-11 сыйныфлар).*

5.4. Бәйгедә катнашучы теләсә кайсы номинациядә татар телендә иҗат иткән әдәби әсәрен тәкъдим итә. Берьюлы 2-3 номинациядә катнашырга мөмкин.

5.5. Әсәр матбугат битләрендә яки китап буларак басылган булырга мөмкин. Каләмдәше (соавторы) мәктәп яшендә булмаган, республика күләмендә оештырылган башка әдәби бәйгеләрдә катнашкан әсәрләр кабул ителми.

5.6. Бәйге эшләренең бизәлешенә таләпләр: word документы, А4 форматы, Times New Roman шрифты 14, 1,5 интервал, читләрдән 2 см. Эшләр электрон форматта гына җибәрелә.

## 6. Бәйгене үткәрү тәртибе

6.1. Бәйгедә катнашучы үзе (яшьтәш соавторы булса, *үзләре*) иҗат иткән әсәрне (берничә номинациядә катнашса, *әсәрләрне*) һәм үзе турындагы анкетаны (кушымта) оештыру комитетына ilhambeygese2015@gmail.com адресына 31 нче гыйнварга кадәр юллый.

6.2. Бәйге ике турда уздырыла:

**1 нче тур.** 1 нче февраль – 1 нче март. Экспертлар төркеме барлык әсәрләр арасыннан иң яхшы шигъри әсәрләрне (һәр яшь категориясендә), иң яхшы проза әсәрләрен (һәр яшь категориясендә), иң яхшы сәхнә әсәрләрен (һәр яшь категориясендә) сайлап ала.

**2 нче тур**. 1 нче март – 1 нче апрель.

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары өчен:**

республика 5 зонага бүленә һәм 2 нче тур аерым муниципаль берәмлекләрдә жюри әгъзалары катнашында үтә. Бәяләүчеләр республика күләмендә төркемнәргә бүленгән район үзәгенә барып, әлеге турга үткән укучылар белән таныша, аларның әсәрләрен тагын бер кат тыңлый һәм нәтиҗә ясый.

**Рәсәй төбәкләре өчен:**

2 нче турга сайлап алынган укучыларның иҗади эшләре үзләре башкаруында видеотасмага яздырылып, оештыру комитетына ilhambeygese2015@gmail.com адресына юллана. Жюри әгъзалары видеоязмаларны җентекләп караганнан соң нәтиҗәләр чыгара.

Жюри 2 нче турда сайлап алынган әсәрләрнең бәяләмәсен карап чыгып раслый һәм алар арасыннан һәр номинация һәм һәр яшь категориясендә 1 нче урын, 2 нче урын, 3 нче урын һәм номинантларны билгели.

1 нче турда җиңгән һәркемгә бәйге лауреаты исеме бирелә һәм җиңүчеләр барысы да йомгаклау кичәсенә чакырыла.

Башлангыч сыйныф укучылары әсәрләре арасыннан иң яхшылары сайлап алынып, аларның авторларына йомгаклау кичәсендә кызыксындыру бүләге тапшырыла.

1 нче турда сайлап алынган әсәрләрдән әдәби альманах бастырыла, алар Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты сайтына урнаштырыла.

6.3. «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы Казан шәһәрендә үткәрелә. Йомгаклау кичәсен уздыру көне оештыру комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә игълан ителә.

6.4. Бәйге нәтиҗәләре, җиңүчеләр турында мәгълүмат Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты сайтларына урнаштырыла.

Кушымта 2

# АНКЕТА

Фамилия, исем: ____________________________________________________

Туган елы: _________________________________________________________

Район: ____________________________________________________________

Шәһәр: ___________________________________________________________

Мәктәп: ___________________________________________________________

Сыйныфы: _________________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат (ирекле): ___________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Әсәр исеме: ________________________________________________________

Номинация: ________________________________________________________

Әсәр күләме (бит): _________________________________________________

Басылып чыккан әсәрләре, еллары, кайда: _________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Хәбәрләшү өчен телефоннар: ___________________________________________

Электрон адрес:______________________________________________________

Өй адресы: _________________________________________________________

Лист согласования к документу № 20231/14 от 23.10.2014
Инициатор согласования: Шакирова Л.М. Ведущий советник отдела национального образования
Согласование инициировано: 22.10.2014 16:21

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахметзянова Л.М. | | Согласовано<br>23.10.2014 - 16:07 | - |
| 2 | Мухаметов И.Р. | | Подписано<br>23.10.2014 - 19:00 | - |